# 17 нче китапханәдә Татар теле һәм мәдәнияте көне

**Ульяновскиның 17 нче санлы «Содружество» китапханәсендә Татар теле һәм мәдәнияте көне узды. «Туган тел» дип аталган әлеге чара татар әдәбияты классигы, мәшһүр әдип Габдулла Тукайның туган көненә багышланган иде.**



«Туган тел» бәйрәмендә мәркәзебез Казаннан килгән мөхтәрәм кунаклар - якташыбыз, шагыйрь һәм язучы, Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге премиясе, М.Җәлил исемендәге яшьләр премиясе лауреаты, РФ Президенты карамагындагы мәдәният һәм сәнгать буенча Совет әгъзасы Ренат Харис һәм язучы, драматург, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты, ТРның Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов катнаштылар. Алар милләттәшләребезгә үзләренең уй-фикерләрен, киңәшләрен, үгет-нәсыйхәтләрен җиткереп, җирле шагыйрьләрне, ана теле укытучыларын кызыксындырган күп санлы сорауларга җаваплар да бирделәр. Ә өлкә татар автономиясе рәисе Рамис Сафин, өлкә татар язучылары берләшмәсе җитәкчесе Равил Шәфигуллин, 17 нче китапханә мөдире Ольга Юрлова һәм китапханәнең татар бүлеге җитәкчесе Гөлфия Самигуллина ерак юлны якын итеп килгән иҗат әһелләренә рәхмәт сүзләрен ирештерделәр.